**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

КАРАР ____________ 13.11.2020 ПР-221 ПОСТАНОВЛЕНИЕ № ___________

«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү кыйммәтенең 2021 елга нормативларын раслау турында»

1. 2021 елга түбәндәгеләрне расларга:

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны 2021 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативларын;

гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмәне.

2. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына тәэмин итәргә:

гомуми белем бирү оешмаларын әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән гомуми белем бирү оешмаларында йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативлары нигезендә финанслауны.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Л.Р.Сираевага йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 0180CD78000CAB95AA4750138BB28C9CD3
Владелец: Габдулхаев Ильшат Ильфатович
Действителен с 21.11.2019 до 21.02.2021

И.И.Габдулхаев

«Актаныш муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге башкарма
комитеты җитәкчесе карары белән
расланган
«__» _______ 2020 № ____

2021 елга гомуми белем бирү оешмаларында балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәя нормативлары

| Автотранспорт чарасы төре атамасы | Ике ставкалы норматив күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка - 1 елга, сумнарда | автотранспорт чарасының бер километрга үткән юлы ставкасы, сумнарда |
| КАВЗ | 149595 | 37,79 |
| ПАЗ | 149072 | 37,72 |
| Газ-«Газель» | 129791 | 30,61 |
| УАЗ | 129338 | 29,21 |
| FIAT | 132984 | 27,71 |
| Peugeot Boxer | 138182 | 27,36 |
| Ford Transit | 138440 | 30,79 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 151544 | 35,91 |

«Актаныш муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге башкарма
комитеты җитәкчесе карары белән
расланган
«__» _______ 2020 № ____

Гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү механизмын билгели (алга таба - муниципаль хезмәт).

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативы, автотранспорт чаралары саны һәм автотранспорт чараларының хисап чорында факттагы үткән юлы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе нормативлары ел саен «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы үткән юлы турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча автотранспорт чарасының автотранспорт чарасы маршрутының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында фактик үткән юлы буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

2.1. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәтен күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

биредә:

$S_i$ – муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m төрендәге автотранспорт чараларының факттагы үткән юлы, километрларда;

$NF_{km_m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда йөртүне оештыру нормативы ставкасы бер километрга, сумнарда;

$NF_{as\,m}$ - гомуми белем бирү оешмалары укучыларын бер автотранспорт чарасы өчен махсус билгеләнгән автобуслар белән йөртүне оештыру нормативы ставкасы, сумнарда;

$M_m$ - m төрендәге автотранспорт чаралары саны, берәмлекләрдә;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус төре атамасы;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар саны.